## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлегенең Татар Шураны торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы**

07 ноябрь 2024 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 07 ноябрьндә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Татар Шураны торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мен) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йоз ) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы»:

1. **Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:
   - Керәш-Шуран һәм Приют-Шуран торак пунктлары арасындагы юлны ремонтлау
   - Мәктәп урамы буенча җәйге юлларны грейдировкалау килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү;
   - Мәктәп урамы буенча юлларны кышкы тотуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
   - юл буендагы уләннәрне чабу
2. **Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**
   - су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау,материаллар,насос сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү;
   - су алу (анализ).
3. **Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**
   - Татар Шураны авылының урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча түләү;
   - светодиодлы лампалар сатып алу;
   - Татар Шураны авылының урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау.
4. **Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**
   - янгын сундеру машинасын карап торган очен килешу буенча тулэу.
   - янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу.

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**
- үләннәрне чабу;
- тозелеш материаллары сатып алу,паркны төзекләндерү.

**6. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**
- Татар Шураны авылы зиратында үләннәрне чабу;
- каты коммуналь калдыкларын чыгару;
- зираттагы агачларны, куакларны кису;

**7. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү**
- Татар Шураны авылы чишмәсен төзекләндерү;
- материаллар сатып алу

**8. Обелискны төзү, ремонтлау (мәдәни объектлар булмаган) Россия Федерациясе халыкларының мирасы (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**
- обелискны ремонтлау.
- аңа якын территорияне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 кеше, бу 53% тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен 40 граждан җыенда катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керәш-Шуран авыл җирлегендә Керәш-Шуран авылы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. 2025 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлегенең Татар Шураны торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000,00 (бер мең ) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, түбәндәге категория гражданнар: 1 һәм 2 төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар өчен 500,00 (биш йөз) сум күләме билгеләргә, локаль конфликтларга һәм Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаганда әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:
- Мәктәп урамы буенча җәйге юлларны грейдировкалау килешүе

буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Мәктәп урамы буенча юлларны кышкы тотуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- юл буендагы үләннәрне чабу

**2. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

-су белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау, материаллар,насос сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү;
- су алу (анализ).

**3. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Татар Шураны авылының урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтүгә килешү буенча түләү;
- светодиодлы лампалар сатып алу;
- Татар Шураны авылының урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау.

**4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- янгын сундеру машинасын карап торган очен килешу буенча тулэу;
- янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу;

**5. Торак пункт территориясен төзекләндерү:**

- үләннәрне чабу;
- тозелеш материаллары сатып алу,паркны төзекләндерү.

**6. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- Татар Шураны авылы зиратында үләннәрне чабу;
- каты коммуналь калдыкларын чыгару;
- зираттагы агачларны, куакларны кисү;

**7. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү**

- Татар Шураны авылы чишмәсен төзекләндерү;
- материаллар сатып алу

**8. Обелискны төзү, ремонтлау (мәдәни объектлар булмаган) Россия Федерациясе халыкларының мирасы (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- обелискны ремонтлау.
- аңа якын территорияне төзекләндерү.

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Керәш-Шуран авылы, Үзәк урамы, 6а йорт, Мөслим муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://muslumovo.tatarstan.ru. һәм ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Керэш-Шуран авыл җирлеге башлыгы ____________ Р.Г.Сафиуллин